**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

**30 декабрь 2015ел** **№26**

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районының
Норлат авыл җирлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында.

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 10,11,93 статьялары нигезендә, Норлат авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 нче елның 28 нче декабрендә кабул ителгән 59 нчы номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»карары нигезендә, Норлат авыл җирлеге Советының 2015 нче елның 28 нче декабрендә кабул ителгән 25 нче номерлы «җирле референдум үткәрү инициативасы турында»карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2016 елның 6 мартына Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2016 елда Норлат авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 200 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

| № | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме (сум) |
|---|---|---|
| | Төзелеш, агымдагы һәм капиталь ремонт, эчтәлек:<br>урамнарны яктырту;<br>- автомобиль юллары, ишегалды территорияләре , квартал ара юллар;<br>-суүткәргеч челтәрләре һәм канализация. | 250 000,00 |
| | Җирлек территориясен, шул исәптән зиратларны төзекләндерү, балалар мәйданчыгын җиһазлау, моның өчен кирәкле төзелеш материаллары һәм кече архитектура формаларын сатып алу. | 160 000,00 |
| | Юлларны паспортлаштыру | 25 000,00 |
| | Янгынга каршы су белән тәэмин итү объектларын һәм чыганакларын (пирслар, краннар, гидрантлар, ясалма сулыклар, сулыкларга керү юлларын төзү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау | 40 000,00 |
| | Йортлар нумерациясе, урамнарны яңарту (күрсәткеч) | 25 000,00 |
| | Барлыгы: | 500 000,00 |

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында) http://zelenodolsk.tatarstan.ru (Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендында Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 нчы йорт адреслары буенча халыкка хәбәр итәргә тиеш. Норлат авылы, М. Фәйзуллин ур., 17 йорт урнаштырырга.

**Норлат**
**авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Р.Р.Багаутдинов**